“Раслыйм”

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
“Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегендә
җир биләмәләреннән файдалану һәм
төзелеш кагыйдәләре комиссиясе рәисе

________________________И.Ф. Рәхимов

2019 елның 17 нче апреле
№ 4

**Ачык тыңлаулар буенча**
**Нәтиҗә**

ТР ЧМР “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге башлыгының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында”гы 2019 елның 12 нче февралендәге 2 номерлы карары нигезендә, ачык тыңлаулар 17.04.2019 ел, 10.00 сәгатьтә Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының зур залында түбәндәге адрес буенча узды: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 йорт.

**Ачык тыңлауларда чишелергә тиешле мәсьәләләр:**

Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты:

1. ЧМР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы мөрәҗәгате буенча:

- “III класслы куркыныч җитештерү-коммуналь объектлар зонасы” ПК-2 төзелешенең территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы, Чистай ш., Бутлеров ур., 141, шул исәптән кадастр номеры 16:54:040301:266, мәйданы 227,0 кв. м., Ж-2 җир кишәрлеге төзелеш зонасына “Урта катлы торак йортлар төзү зонасы” чикләрендәге территорияне кертү өлешендә;
- Д-1 “Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона” төзелешенең территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы, Чистай ш., К.Маркс ур., 35, чикләрендәге территорияне, шул исәптән кадастр номеры 16:54:100402:308 булган җир кишәрлеген “Мәгариф һәм фәнни комплекслар урнаштыру зонасы” Д-3 төзелеш зонасына кертү өлешендә.

2. Гражданин Р.Х. Галиев мөрәҗәгате буенча, Р-1 “Рекреацион-ландшафтлы территорияләр зонасы” территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы, Чистай ш., К. Маркс ур., 92 Б, шул исәптән кадастр номеры 16:54:150102:0054 булган җир кишәрлеген, “Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона” Д-1 төзелеш зонасына кертү өлешендә.

3. Гражданка Ю.А. Зверева мөрәҗәгате буенча, Р-1 “Рекреацион-ландшафтлы территорияләр зонасы” төзелеш зонасы чикләрен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы, Чистай ш., Җиңүнең 40 еллыгы, 4-в, шул исәптән кадастр номеры 16:54:150102:37, мәйданы 300 кв. м., Д-1 “Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона” төзелеш зонасына кертү өлешендә.

**Карар иттеләр:**

1. Чистай шәһәр Советының 2018 елның 27 июлендәге 26/2 номерлы карары белән расланган ачык тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең 2019 елның 17 апрелендә 10 сәгать 00 минутта билгеләнгән җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссия утырышы, кворум булмау сәбәпле, 22.04.2019 елның 22 апреленә 10.00 сәг. күчерелә.

2. Әлеге бәяләмәне ТР Хокукый мәгълүматның рәсми порталында(pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Комиссия сәркатибе: ________________________М.Р.Бибишев